| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ<br>ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.12.2021е. № 18

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген раслау турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.2 маддәсендәге 4 пунктының дүртенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр җирлеге башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының кушымтада бирелгән баш администраторлары исемлеген расларга.
2. Әлеге карар Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына бюджеттан башлап кулланыла.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Алексеевск муниципаль районы**
**Алексеевск шәһәр җирлеге**
**башкарма комитеты җитәкчесе** **И.К. Свистунов**

Татарстан Республикасы Алексеевск
муниципаль районының Алексеевск
шәһәр җирлеге башкарма комитетының
2021 елның 09 декабрендәге
18 номерлы карарына кушымта

## Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеге

| Бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторы исеме | Бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторы коды | Бюджет кытлыгын финанслау чыганагы төркеме, төркемчәсе, маддәсе һәм төре коды | Бюджет кытлыгын финанслау чыганагының төркеме, төркемчәсе, маддәсе һәм төре атамасы |
|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы | 501 | 01 05 02 01 13 0000 510 | Шәһәр җирлекләре бюджетларының калган башка акчаларын арттыру |
| Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы | 501 | 01 05 02 01 13 0000 610 | Шәһәр җирлекләре бюджетларының калган башка акчаларын арттыру |